ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“ 17 ” октября 2025 ел** **№ 158**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халык күп җыела торган урыннарны билгеләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында” 2024 елның 24 июлендәге 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланылырга тиешле халык күп җыела торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлек паспортлары формаларын раслау турында” 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары нигезендә, халык күп җыела торган урыннарның террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә юнәлдерелгән көчләрне берләштерү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында халык күп җыела торган урыннарын тикшерү һәм билгеләү буенча ведомствоара комиссия төзү турында” 2024 елның 24 июлендәге 82 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) - преамбулада “25.04.2015” саннарын “25.03.2015” саннарына алмаштырырга;

2) - халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составын, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Р.М. Гатиятовка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Г. Хисаметдинов

*Арча муниципаль*
*районы башлыгының*
*«17» октября 2025 ел, № 158*
*карарына 1 нче кушымта*

**Халык күп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Реңат Мансур улы | – Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе; (килешү буенча); |
| Халиков Айдар Фатых улы | – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Арча районы буенча кураторы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча). |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Гайнетдинов Фәнил Фәим улы | – Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча); |
| Гыйлмуллин Раил Гомәр улы | – Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе Арча һәм Әтнә муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше районара бүлеге башлыгы эчке хезмәт подполковнигы (килешү буенча); |
| Касыймов Рөстәм Фәрид улы | Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>кешеләр яши торган урынның милекчесе яисә кешеләрнең күпләп була торган урыныннан башка законлы нигездә файдаланучы зат (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Рамил Рәшид улы | – Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге “Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш сак идарәсе” Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы начальнигы (килешү буенча); |
| Юзаев Искәндәр Илнар улы | – Арча янгын-коткару гарнизоны җитәкчесе – -Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе ГПС ФПСның 107 нче ПСЧ 7 нче ПСО җитәкчесе (килешү буенча); |
| Зәйнуллин Илназ Минсур улы | – Арча муниципаль район башлыгы ярдәмчесе. |